ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**28.02.2022** **г.Чистополь** **№ 143**

2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 статьясына таянып, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» коммерциясез партнерлыгы турындагы 2022 елның 7 февралендәге 37 номерлы хатка нигезләнеп Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнарның максималь керем күләмен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары милкендәге һәм гаиләнең һәр әгъзасына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме - 306 423 сум.

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме - 8904 сум.

3. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарның 1.1 пунктларында һәм 2 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне кулланырга, гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов